СОВЕТ НУРИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НӨНӘГӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

«19» декабрь 2025 ел №16 Нөнәгәр ав

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Советы Регламентына өстәмәләр кертү турында**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге Советы карар итте:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге советы карары №14 20.12.2010 ел белән расланган ( 30.05.2023 ел №85 үзгәрешләр белән) Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге Советы Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.Регламентның 35 статьясына түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Карар кабул ителгәндә депутатларның хәлиткеч тавыш хокукына ия "хуплап" һәм "каршы" бирелгән тавышлары саны тигез булган очракта, Совет утырышында рәислек итүче тавыш хәлиткеч бул.».

2. Әлеге карар имза салынган вакыттан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җәмәгать тәртибен төзекләндерү, төзү, яклау буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Нөнәгәр авыл
җирлеге советы рәисе: И.Н. Закиров